وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә
Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз!
Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп,
төрле юлларга китмәгез!

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№3 (120). 20 гыйнвар 2012 / 26-сафәр-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Мөселман партиясе – төп максат түгел ▷2◁



XVII гасырдагы татар мәдрәсәләре ▷3◁



Бисмиллалы бал ▷4◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

### ГОЛӘМӘЛӘР ШУРАСЫ ҺӘМ КАЗЫЯТ УТЫРЫШЛАРЫ УЗДЫ

16 гыйнвар көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә Голәмәләр шурасының чираттагы утырышы узды. Утырышта "Хәләл" стандарты комитеты эшчәнлеге (шул исәптән, хайваннарны чалу белән кем шөгыльләнергә тиешлеге); комитет сертификаты булмыйча, төрле ит товарларына мәчет сурәтләрен төшереп, сатып алучыны аптырашта калдыручы оешмаларга карата эшне ничек алып бару; шешәләрдә сатыла торган суның ничек сертификацияләнергә тиешлелегенә кагылышлы мәсьәләләр карап үтелде. Шулай ук мәчетләр каршындагы курсларда һәм читтән торып белем алучы шәкертләр өчен яңа уку әсбапларын лицензияләү дә тикшерелде. Мөслимәләр турында яңа фильм сценариесе дә шура әгъзалары тарафыннан бәяләнде һәм аңа берникадәр үзгәрешләр кертергә тәкъдим ителде. Әлеге мәсьәләләр буенча Голәмәләр шурасы әгъзалары, үз фикерләрен белдереп, тәкъдимнәрен җиткерде, карарлар чыгарды.

Дүшәмбе көнне иртән Диния нәзарәтендә Казыят утырышы да булды. Утырышта республикабызның төньяк-көнбатыш төбәге казыяте хисабы тыңланды.

### БУАДА - КОРЪӘН УКУ БӘЙГЕСЕ

Буа районы мөхтәсибе Рөстәм хәзрәт Хәйбуллов хәбәр итүенчә, Буада гыйнвар башындагы озын ялларда, вакытны бушка сарыф итмичә, файдалы һәм саваплы эшләр башкарып калырга тырышканнар. Шуларның берсе - балалар арасында Коръән уку ярышлары. Бәйгедә өчтән алып унике яшькә кадәрге балалар катнашкан.

### КУКМАРАДА - МӘҮЛИД АШЛАРЫ

Шушы көннәрдә Кукмара мәдрәсәсе шәкертләре Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев белән очрашты. Очрашу барышында яшьләр үзләрен кызыксындырган күп кенә сорауларга җавап таба алды.

Кукмара районы авылларында Мәүлид ашлары үткәрелә башлаган. Аш-Бужи, Уразай авыллары мөселманнары мондый табыннар корырга өлгергән дә инде. Тиздән бу саваплы эшне районның башка авыллары да дәвам иттерәчәк, дип хәбәр итте Кукмара мөхтәсибе Зиннур хәзрәт Сәмигуллин.

### ТИМЕРАЯКТА ШУУ ЯРЫШЛАРЫ ҮТТЕ

15 гыйнварда ТР мөселманнары Диния нәзарәте Казан шәһәренең 41 нче мәктәбендә (Вахитов районы) мөселман яшьләре арасында тимераякта шуу буенча ярышлар үткәрде. Бәйгедә Казанның Мәрҗани, Солтан, Рамазан, Әҗем, Ал, Кабан арты, Фәрхәд, Әниләр, Салихҗан, Борнай, Өметлеләр, Ризван мәчете командалары, шулай ук РИУ студентлары, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә шәкертләре катнашты. Нәтиҗәдә, I урынга Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәнең II курсында укучы Рамил Гыйльманов лаек булды. II һәм III урыннарда - Кабан арты мәчете командасы вәкилләре - Айназ Зарипов белән Булат Насыйбуллин. Җиңүчеләргә дипломнар, медальләр һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды.

***Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

# ХАТА-КИМЧЕЛЕКЛӘРЕБЕЗНЕ ТӨЗӘТИК!

## (Вәгазь)

**Коръәни-Кәримдә Аллаһы Тәгалә: "Ә ләстү бираббикум" (Мин сезнең Раббыгыз, Тәрбиячегез, гыйбадәт кылырга тиешле, бердәнбер Илаһыгыз түгелмени?), дип Үзен танытты. Шулчак: "Шәһиднә иннәкә Раббунә" (Шәһадәт кылабыз, ант итәбез, Син - безнең Раббыбыз), дип бу дөньяга киләчәк җаннар Аллаһы Тәгаләгә ант иттеләр, дигән аять китерелә.**

Бу вакыйга дөнья барлыкка килгәнче күп заманнар элек була. Һәм ул шәригатьтә "әлмисак", ягъни җаннарның Аллаһы Тәгаләгә вәгъдә биргән "көне" буларак билгеләнә.

Ягъни Аллаһы Тәгалә кешеләрнең җаннарын Үзенең каршына тезеп бастырып, дөньяда яшәгән вакытыгызда, тән белән берлектә яшәгәндә: "Мине онытмассызмы? Кушканнарымны үтәрсезме? Явызлыктан, хәрамнан тыелып, бер-берегезне рәнҗетмичә ахыр гомерегезгә чаклы яшәрсезме?" - дип ант эчерә. Адәм балаларының җаннары:

- Әлбәттә, Раббыбыз, Син кушканнан тайпылмабыз, үтәрбез, - дип ант итәләр. Әмма араларында ялганлаганнары да булды. Ләкин Аллаһы Тәгалә аларның әйткән сүзләрен үтәмәячәкләрен белеп торды. Аллаһы Тәгалә бар нәрсәне дә Белүче, Күрүче.

Коръәннең бу аяте адәм балалары иманлы, итагатьле, тәкъва булырга тиеш икәнлекләрен аңлата.

Иманлы булу - Аллаһны танып, һәрдаим үзеңне Аның каршында, әлмисакта басып торган кебек, хис итеп йөрергә кирәклеген белдерә.

Итагатьлелек - Аллаһы Тәгаләнең әмер боерыкларын, пәйгамбәребезнең (сгв) әйткән сүзләрен күңелгә салып, буйсынып, карусыз тормышка ашыруны аңлата.

Тәкъва булу - Аллаһның тыйган нәрсәләреннән тыелып, кушканнарын үтәп, Раббының ризалыгын югалтудан куркуны күз алдында тота.

Адәм балалары бу дөньяга килгәч, җан-тән белән берлектә булганнан соң, биргән вәгъдәләрен, антларын искә төшерер өчен, Раббыбыз - Кодрәт иясе - пәйгамбәрләр һәм китаплар җибәргән. Адашып-саташып йөрмәсеннәр өчен дин, шәригатьне булдырган. Мисал өчен, Коръәндә: "Аллаһы Тәгалә сезнең тышкы кыяфәтләрегезгә карап түгел, күңелегезне күзәтеп хөкем итә, кылган гыйбадәтләрегезне кабул итә", - дип әйтелә. Шулай ук пәйгамбәребез дә: "Зур мөлкәткә ия булган кеше бай булып саналмый, күңеле киң кеше бай булып санала", - ди үзенең хәдисләренең берсендә (Бохари). Димәк, безгә күңелләребезне пакьләү юлында күп көч куярга кирәк. Күңел көзгесе (калеб) чиста, пакь булмаса, диннән дә чыгып китү мөмкинлеге бар икәнлеген пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) белгертә.

"Аллаһы Тәгалә белән ант итәм: чын мөселман булмыйча торып, берегез дә җәннәткә кермәячәксез. Бер-берегезгә карата күңелегездә мәхәббәт булмыйча торып, чын мөселман була алмаячаксыз. Бер-берегез белән сәламләшкәндә чын күңелдән сәламләшегез. Һәм бер-берегезне күрә алмаучанлык хисеннән сакланыгыз, чөнки ул үткер пәке кебек. Ул пәке (бер-береңне күрә алмаучанлылык) чәчләрне кыра торган түгел - ул күңелдән динне кырып ала, динсез калдыра", - дип әйтә пәйгамбәребез (сгв) (Бохари).

Күңел дигәнең (калеб) бик нечкә нәрсә икән. Чиста, пакь булса, ихласлык саклана торган хәзинә ул. Анда акыл урнаша. Бу мәсьәләдә пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (сгв) тарафыннан әйтелгән бик матур сүзләр бар: "Акыл калебтә, күңелдә урнашкан. Рәхим-шәфкатьлелек - бавырда. Мәрхәмәтлелек талакта була. Ә сулыш үпкәдә урнаштырылган" (Бохари).

Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә: "Иң хәерлеләрегез Аллаһы каршында тәкъварак булганыгыз", - ди. Ягъни Раббыбызның кушканнарын үтәргә атлыгып торучылар, Аның ризалыгын югалтудан куркучылар. Тәкъва кеше һәрвакыт үзен начарлыктан төзәтү өстендә эшли торган була. Холкын тәртиптә тотарга тырыша. Чөнки ул һәрчак пәйгамбәребезнең (сгв): "Иң хәерлеләрегез Исламда иң яхшы холыклы булганнарыгыз, динне аңлый торган булсалар, әлбәттә", - дигән сүзен исләрендә тоталар, аңнарыннан, зиһеннәреннән чыгармыйлар. Алар башкаларга тел тидермиләр, мыскыл итмиләр, яла якмыйлар.

Чөнки: "Аллага ышанган кеше икенче берәүгә яла якмый, аны ләгънәт кылмый, сүкми һәм аңа карата пычрак гамәлләр эшләми", - дип кисәтә Мөхәммәд (сгв).

Югарыда китерелгән аять-хәдисләрдә күрсәтелгәнчә, күңелләребезне чиста тотсак, шуның бәрабәрендә җаннарыбызның "әлмисакта" биргән антларын искә төшереп, холыкларыбызны тәрбияләргә тырышсак, хәлләребез башкачарак булыр иде.

Ә бит бүген, без - мөселманнар арасыннан кайберләребез бер-берләрен күрә алмый, дошманлык кыла. Бер-берләре турында гайбәтләр сатып, ялалар ягып, күңелләрендәге иман очкыннарына игътибар итмичә, хискә бирелеп, нәфесләрен симертә. Әгәр, чыннан да, дингә бирелеп, Коръәндәге һәм хәдисләрдәге сүзләрне истә тота торган булсак, бер-берләребезне рәнҗетер идекмени?! Бүген сөйли, яза торган сүзләребез чынлыкта дин өчен түгел бит, ә фәкать үзебезне өскә чыгарып, фикеребезне киң мәйданга таратып, үзебезне барысыннан да акыллырак, гыйлемлерәк итеп күрсәтү генә.

Барыбыз да "дин, дин" дип сөйләшәбез, Коръәннән, хәдистән төпле дәлилләр китергән булабыз, тик барысы да үзебезнең нәфесләребезне иркәләр өчен генә. Нишләп Аллаһы Тәгалә фикере өстен булырга тиеш түгел соң? Әллә без Аңардан акыллырак булдыкмы инде? Күңел көзгебез пычрак килеш, элеккеге галимнәр дәрәҗәсендә булмакчы булып, ни өчен без Коръән аятьләренә һәм хәдисләргә үзебезнең пычрак нәфесләребездән кайнап чыккан мәгънәләрне салырга тырышабыз соң? Әлбәттә, бу сорауларның җавабы бик гади. Күңелләребез пычрак. Кылган гамәлләребез нәфесләребезгә ияреп кенә, кеше алдында күрсәтер өчен генә. Чөнки кая барасыбыз турында төптән уйламыйбыз. Наданлыгыбыз чиктән ашкан. Галимнәрдән гыйлем өйрәнер урынына, нәфесләребезгә хуш килгән, фикерләребезгә туры килгән мәгълүматны гына ала алабыз. Гыйлемгә хирыслык юк. Холкыбызны үзгәртә алмыйбыз, чөнки нәфсебезне җиңә алмыйбыз. Нәфесне җиңәр өчен, Аллаһы Тәгалә турында күбрәк уйларга кирәк, ә без аны булдыра алмыйбыз, чөнки тәкәбберлегебез юл бирми.

Ләкин бер нәрсәгә дә карамастан, безгә Аллаһы Тәгалә каршында күңелләребезне чистартырга, холкыбызны пәйгамбәребез (сгв) кушканча тәрбияләргә кирәк. Моның өчен бердәм булырга, кеше хатасын тикшергәнче, үзебезнең ялгышлыкларыбызны төзәтү зарур. Нәфсебезне тыярга, иман, итагать, тәкъвалыкны үстерү юлында тырышырга кирәк. Әлмисакта биргән вәгъдәләребезне һәм пәйгамбәребезнең (сгв) шул мәсьәләдә сөйләнгән соңгы вәгазен истә тотарга кирәк. Иншә Аллаһ, шулчак күңел көзгесендәге тутыклар китәр һәм анда хакыйкый дин, иман чагылышы табылыр!

***Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***

# АЕРЫЛМАГЫЗ, БУЛСА ДА "СӘБӘП"ЛӘРЕ...

**Кама буе казыятенә дүрт мөхтәсибәт: Чаллы, Түбән Кама, Тукай, Алабуга мөхтәсибәтләре керә.**

Әңгәмәбез - Кама буе төбәге казые, Татарстанның Диния нәзарәте Президиумы әгъзасы, Чаллыдагы "Ак мәчет" имамы һәм шул мәчет каршындагы мәдрәсә ректоры Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев белән. Ул безне казыятне борчый торган мәсьәләләр, халык еш мөрәҗәгать итә торган сораулар һәм әлеге төбәк "үзенчәлеге" - сәләфиләр белән килеп туа торган каршылыклар белән таныштырды. Соңгы вакытта мөселман гаиләләрендә гакыйдә белән бәйле аңлашылмаучанлыклар туып, аерылышу өчен казыйга килү очраклары күбәеп киткән.

- Гади халык үзара эш мөнәсәбәтләре (килешүләрне үтәмәү), ир белән хатын арасында килеп чыккан мәсьәләләрне чишү уңае белән мөрәҗәгать итә. Халкыбыз өчен традицион булган хәнәфи мәзһәбе буенча, кем дә кем: "Ләә иләһә иллаллаһу Мөхәммәдур-рәсүлүллаһ", - дип әйтсә һәм шушы сүзләрнең мәгънәсенә төшенеп, аны күңеле белән кабул итсә, ул кеше мөселман булып санала. Ә үзләрен сәләфиләр дип йөрүчеләрнең карашынча, мөселман булу өчен югарыда әйтелгән шарт кына җитәрлек булып саналмый, бар гыйбадәтен җиренә җиткереп үтәгән кеше генә мөселман була ала. Аларның: "Кеше үзен мөселман дип саный икән, бу берни дә аңлатмый, ул гамәлгыйбадәт кылса гына мөселманнан хисаплана", - дип йөрүләре - җәмгыятебездәге аңлашылмаучанлыкларның килеп тууына сәбәпче булды. Өстәвенә, сәләфиләр, кешенең гамәле үзләренә ошау-ошамауга карап, тәкъфир кылалар (ягъни, бер сүз белән әйткәндә, кешене кяферлеккә чыгаралар), - дип башлады үз сүзен Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев. - Шундый очраклар да була: ничәмә-ничә ел бергә торып, әби-бабай яшенә җиткән гаиләләр аерылышырга мөмкин. Чөнки ир яисә хатын берсе үзен мөселман дип йөрсә дә, әдәп-әхлаклы булса да, гыйбадәте охшамавы сәбәпле генә икенчесе тарафыннан кяфер булып танылырга мөмкин. Хәтта намаз укыган, башка гамәл-гыйбадәтен кылган кеше дә, әгәр "гакыйдәсе дөрес булмаса", кяфер булып чыга ала. Әле күптән түгел генә алтмыш яшьләрдәге бер ханым да үзенең ирен кяферлеккә чыгарып, "Аны? белән бергә тору дөрес микән?" дип борчылып килде. Ни өчен ул кяфер соң дигәч: "Ул минем башка мөселман хатын-кызлары белән бергә җыелып дин гыйлемен өйрәнүемә риза түгел", - ди.

**- Кешеләр вәсвәсәләргә бирелмәсен, төрле чит-ят фикерләргә бирешмәсен өчен нинди профилактик чаралар күрергә кирәк соң? Сез китергән бер мисалдагы "кяферлеккә чыккан бабай" гамәл кылмый башлаган түгелдер бит инде...**

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

# АЕРЫЛМАГЫЗ, БУЛСА ДА "СӘБӘП"ЛӘРЕ...

- Юк, алай түгел. Бу ханым (гадәттә, алтмыш яшьтә булуларына карамастан, алар үзләрен әби дип әйткәнне яратмыйлар) укырга дип иртән чыгып китә дә кич кара?гыда гына кайтып керә. Ирене? рөхсәтеннән башка, кайда йөргәнлеге билгеле булмаган хатыны белән нинди ир риза булыр икән? Хатын-кыз беренче чиратта ирене? ризалыгына ирешергә тиеш.

Моннан ике-өч ел элек югары урында эшли торган дәрәҗәле бер кеше үзенең хатынын һәм ике кызын дини белем алырга мәчеткә җибәрә. Ә ул исә сәләфиләр кулына килеп эләгә. Алар исә, үз чиратында, ул ханымны? "гакыйдәсен дөресләгәч", "кяфер" иреннән аерып, башка кешегә кияүгә биреп җибәрә. Нәтиҗәдә, гаилә таркала, гамәл-гыйбадәтен кылмаса да үзен мөселман дип санаган ир ислам диненнән баш тарта һәм үзен ислам динене? дошманы дип игълан итә. Бер генә кешене ислам диненә кертүдә сәбәпче булган кешегә җәннәт вәгъдә ителә, ә ислам диненнән чыгаруга сәбәп булган кешене нәрсә көтүе турында ничек уйларга мөмкин?

Бүгенге көндә ирләр дә, хатын-кызлар да үзләрене? өстендәге бурычларын тиешенчә үтәмиләр, аннары гаепне өсләреннән төшерү өчен берсен-берсе кяферлеккә чыгаралар, ә сәләфиләр гакыйдәсе мо?а туры юл ача: кимчелексез кеше юк, шу?а күрә үзе?ә ошамаган һәрбер кешене кяферлеккә чыгарырга була. Ә кяфер белән ни теләсә?, шуны эшләргә була.

**- Ә ни сәбәпле кешеләрнең фикерләре кисәк кенә үзгәреп китә?**

- Бу кешене гипнозлагандагы кебек бара. Әйтик: "Пәйгамбәребез (сгв) намазны болай укыган, аның вакытында шулай булган", - дип, белсәләр дә, белмәсәләр дә гел тукып торалар, үзләрене? кү?елләренә ошаган мәгънәләр бирәләр, үзләрене? фикерләренә башкаларны ышандыралар. "Коммунизм, коммунизм" дип тукый торгач, күпме халык шу?а ышанды. СССР системасы җимерелеп, үзгәртеп корулар башлангач, без гарәпләрне пәйгамбәр кебек кабул итә башладык. Мин үзем 1988 елда намазга бастым. Ул вакытта намаз укучылар бармак белән генә санарлык иде. Ә нәрсә, алайса ул елларда калган кешеләр - Россиянең бар халкы да диярлек кяфер булган булып чыга идеме? Ул вакытта күпләр кү?елләреннән үзләрен мөселман дип санасалар да, гамәлләрен кылмыйлар иде, хәтта хәмер кабучылары да аз түгел иде. Без бит алар үзләрен мөселман дип санаганнары өчен генә, гамәл кылмаучы, бәлки телдән генә үзләрен мөселман дип санаучыларны? балалары, оныклары булган өчен генә мөселман булып йөрибез. Башка дин әһелләрене? балалары үзләрен мөселман дип йөрмиләр бит, хәтта кү?елләре белән ислам динене? хаклыгына ышансалар да. Никадәр генә гөнаһлары булса да, алар берсен-берсе кяфер дип атамаганнар. Бүгенге көндә менә шуны да аңлау җитми безне? халыкка. Дөрес, безнең бөтенебезнең дә пәйгамбәребез (сгв) кебек яшисе килә. Шу?а күрә бүген үзләрен кайберәүләр сәләфиләр дип атый. Сәләфиләр дип беренче мөселманнарны атыйлар. Аларга ошарга тырышу бик яхшы, әмма бу телдә генә булмасын һәм нәрсә генә эшләсә? дә бу исем артына качып эшләмәсә? иде. Ә бит беренче сәләфиләр берсен-берсе кяферлеккә чыгармаган, берсене? гыйбадәтен берсе тикшермәгән, алар динсез кешеләрне дингә өндәгән, үзләрене? күркәм әхлаклары белән башкаларга үрнәк булырга тырышкан. Ә бүген үзләрен сәләфи дип атаучылар башка мөселманнарны? кимчелеген тикшерү белән мәшгуль. Башкаларны дәүләтнең хокук саклау урыннарына бармаска чакыралар, ә үзләре баралар, банклар белән эш йөртмәскә чакыралар, ә үзләре банктан кергән акчаны кулланудан тартынмыйлар. Мөселманнарны кяферлеккә чыгарып, аларны? җанын, канын, малын үзләренә хәләл итеп чыгарган беренче төркем дүртенче хәлифә Гали (рг) вакытында чыга һәм аларны һавариҗлар дип атыйлар. Һавариҗлар мөселманнар арасына таркаулык кертәләр, алар динсезләргә каршы түгел, бәлки мөселманнарга каршы көрәшкә күтәреләләр. Бүген дә үзләрен сәләфиләр дип атаучылар динсезләрне дингә өндәү белән шөгыльләнми, ришвәт алуга, наркоманиягә, эчүчелеккә каршы көрәшми, алар көне-төне урамда азып-тузып, эчеп-косып йөргән кешегә дә бернинди дә йогынты ясамый, бәлки, алар мәчетләргә кереп ислам динен тота торган кешеләр арасында фетнә салалар. Мәзһәбләргә бүленү - зур ялгышлык, дип, аларны? төп көрәш фронты булып мәзһәбләргә иярүче мөселманнарга каршы көрәш тора. Алар үз эшләрендә җәмгыятьтәге кимчелекләрне дә бик оста файдалана. Егерме ел буе ислам турында а?лату һәм уку-укыту да бер яклы гына барды. Безне? халык монда килгән гарәп укытучыларын гына түгел, хәтта гарәп илендә күпмедер вакыт булып кайткан үзебезне? яшьләребезне дә "изгеләрдән" дип кабул итте. Алар анда укыганмы, әллә тик кенә ятканмы, анысын сорап та тору булмады. Һәм бүгенге көндә зур галим булып йөрүчеләрне? күбесе дүрт еллык уку йортыны? ике елын ун ел дәвамында укып, үз илендә укытырга да хокукы булмаган шәех (аларны? да күбесе халыкка билгесез) янына йөргән. Шулар безгә чит фикер, безне? халык өчен ят юнәлеш алып кайтты һәм егерме ел буе халыкка бу чын ислам дип а?латты. Кешегә: "Син җүләр", - дип көне-төне такылдап торсаң, аек акыллы кешенең дә үзен җүләр дип йөри башлавы кебек килеп чыга инде бу...

**- Мондый тискәре күренешләргә каршы тору өчен бездән нәрсә таләп ителә?**

- Диния нәзарәтенең билгеле бер төпле юнәлеше булып, ул дәүләт тарафыннан яклау алырга тиеш. Һәр мөселман дәүләте билгеле бер мәзһәбне генә тота. Мәзһәбсез бер генә дәүләт тә юк. Безнең мең елдан артык тоткан үз юнәлешебез бар, ул - хәнәфи мәзһәбе. Эшебез - дәүләт белән бергә барырга тиеш. Әгәр дә һәр мулла үзе теләгәнчә дин тотса, бу бер дә яхшыга китермәячәк. Соңгы елларда гакыйдә тикшерү модага кереп китте. Бер ун еллап элек интернетта: "Дөрес гакыйдәле кешегә генә кияүгә чыгам" яисә "Дөрес гакыйдәле кешене генә хатынлыкка алам" дигән игъланнар барлыкка килгән иде, ә хәзер исә: "Гакыйдәң дөрес түгел", - дип, аерылышучылар да барлыкка килде. Егерме бишәр-утызар ел бергә торган гаиләләр таркалмасын өчен нишләргә соң? Чыгу юлларын югарыда әйтеп уздым инде: дәүләт күләмендә билгеле бер юнәлеш кенә булырга тиеш. Ләкин аны казый берүзе генә хәл итә алмый. Казый фәкать үзенә мөрәҗәгать ителгән эшләрне карый, тикшерә һәм хөкем чыгара ала. Бу очрактагы кебек күпчелек очракта эш казыйга мөрәҗәгать ителмичә кала. Эш казыйны? белемлелеге, белемсезлеге сәбәпле түгел, ә бәлки мәзһәбкә иярүе сәбәпле казый үзе үк "кяфер" дип игълан ителә. Талак мәсьәләсен алар (сәләфиләр. - Н.С.) "шәригатьчә" хәл итәбез дип әйтсәләр дә, ни өчендер, мал бүлешә башлаганда үзләре үк башкаларны тыя торган дәүләт хокук саклау органнарына (ягъни "тагут" судларына) мөрәҗәгать итәләр. Проблемалар эзләп йөрү - казый (дини судья) вазифасы түгел, проблемасы булган кеше үзе казыйга килеп мөрәҗәгать итә. Мин Чаллының "Ак мәчет"ендә кабул итәм, ишекләр һәрчак ачык. Төп кабул итү вакытым - җомга көн (көндезге өчтән кичке сәгать бишкә кадәр). Алдан хәбәр итеп килергә кирәк.

Сәләфиләр намаз мәсьәләсен үзләренчә "хәл итте" инде, хәзер гаилә проблемасына килеп керделәр. Гаилә, торгызып булмаслык итеп таркалып беткәч, со? була инде. Тагын бер нәрсә бар: сәләфиләрнең "башлык"лары ризалык биргәч, күп очракта казыйның кирәге дә шуның кадәр генә була инде...

***Рәсемдә (уртада):*** **Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев төбәк казыяте җыелышында чыгыш ясый.**

*Әңгәмәдәш -*
*Нияз САБИРҖАНОВ*



# Мөселман партиясе төп максат түгел



***Протоиерей Всеволод Чаплин үткән атнада янәдән Россиядә православие партиясен булдыру фикере белән чыкты. Чаплин үз блогында белдергәнчә, Рус православие чиркәве, әлбәттә, үзе бу эшне башлап йөрмәячәк. Әмма башка кешеләр мондый фикерне тәкъдим итеп, партия оештырсалар, хуплаячаклар гына.***

Россиядә дини партияләр оештыру мөмкинме? Мөселман партиясен булдыру кирәкме? ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең мәгариф һәм фән бүлеге җитәкчесе Вәлиулла хәзрәт Якупов фикеренчә, бу - мөселман өммәтенең беренчел максаты булырлык мәсьәлә түгел. "Россиядә 1917 елгы инкыйлабка кадәр мөселманнар хокукларын яклаучы "Иттифакъ әл-мөслимин" партиясе булган, - ди Вәлиулла хәзрәт. - Димәк, мөселман партиясен оештыруга тарихи нигез бар. Әмма ул вакытта, православие - дәүләт дине була. Башка диннәр, шул исәптән ислам да, икенче статуска ия иде. Бүген ислам дине, башка диннәр кебек үк, бер хокукка ия. Дини партияләр катнашында кешеләрнең хокукларын яклауның кирәге юк".

Шулай да, киләчәктә, сайлаулар, сәяси партияләргә кагылышлы кануннар либеральләштерелү шартларында, мөселман партиясен оештыруның мөмкин хәл булуы турында да искәртә В.Якупов. Бүген исә Дәүләт Думасына үткән партияләр исламга каршы түгел һәм алар традицион диннәрнең, шул исәптән, мөселманнарның да хокукларын якларга әзер.

*Илмир ХӘБИБУЛЛИН*

# Иранга каршы санкцияләр кем файдасына?

***Икътисади проблемалар кичергән Америка (АКШ) һәм башка Көнбатыш дәүләтләр өчен Ираннан гел куркыныч янаган ил итеп күрсәтергә тырышуның асылында ни ята?***



АКШ Иран белән кабат яңа көрәш башларга җыена. Әлеге көрәштә төп корал - нефть. Америка нефть өлкәсендә Иран икътисадына бу юлы тирәнрәк йогынты ясарга ниятли. Чөнки соңгы вакытта Иранда инфляция көчәю аркасында икътисади хәл яхшылардан түгел. Яңа чикләүләр кертеләчәк Иранда соңгы арада азык-төлек бәяләре 40 процентка кадәр артты.

Иранда керемнең зур өлеше исә нефть сатудан килә. Хәзер Америка Иранны нефть керемнәрен бетерү аша буйсындырырга тырыша. Иранга каршы кертеләчәк чираттагы санкцияләр Иранның читкә нефть сатуына комачаулау максатын куя. Президент Барак Обама әлеге санкция турындагы карарга кул куйгач, Иранның акча берәмлеге (риал) АКШ доллары каршында көчен җитди рәвештә югалтты.

**САНКЦИЯНЕҢ ДӨНЬЯ ИКЪТИСАДЫНА ЙОГЫНТЫСЫ**

АКШның санкция карарыннан соң, Иран Басрада хәрби күнегүләрен көчәйтеп, Ормуз бугазында нефть әйләнешен туктатачагын белдердерде. Ә дөньяга сатылган нефтьнең 40 проценты әлеге бугаз аша үтә. Бу гамәл Иран икътисадына гына түгел, дөнья икътисадына да зыян салырга мөмкин, бигрәк тә Европага.

АКШ бу көрәштә бөтен дөньяны үзен якларга чакыра. Европа да, АКШның күңелен күрер өчен, АКШны яклаячагын белгертте. Европа берләгеннән соң, АКШның төбәктәге зур союздашы Согуд Гарәбстаны да шартсыз рәвештә санкцияләргә кушылачагын әйтте.

*Мәкалә www.tatartime.com сайтыннан кыскартып алынды*

# Җинаятьләр саны кими

***ТР Эчке эшләр министрлыгының матбугат үзәге хәбәр итүенчә, Тикшерү комитеты 2011 елга нәтиҗәләр ясады. Реформалар нәтиҗәсендә тикшерү комитеты структурасындагы ике йөзгә якын хезмәткәр кыскартылуга карамастан, бар күрсәткечләр дә яхшырган. Тикшерүгә кертелгән эшләрнең гомуми саны - 37 меңнән артык. Бу 2010 ел белән чагыштырганда, 12 процентка азрак. Ягъни, республикада җинаятьләр саны кими, дигән сүз.***

Бу күрсәткечләр, әлбәттә, хокук саклау органнарының эшчәнлеге белән турыдан-туры бәйле. Әмма бу саннарга дин эшлеклеләре дә үз өлешен керткән, дип исәпләргә мөмкиндер. Нинди генә чикләүләр, җәзалар булмасын, "кешенекенә тимә", "золым кылма" кебек төшенчәләр адәм баласының акылында, йөрәгендә булмаса, нәтиҗәгә ирешеп булмый. Моның өчен исә күңелдә ислам нуры булырга тиеш.

Шул максаттан, республиканың дин эшлеклеләре зур эш башкара. Мәчетләрдә балаларга кечкенәдән ислам дине нигезләрен өйрәтү өчен курслар уза. Дини белем алырга теләүчеләр өчен дә бөтен мөмкинлекләр ачык. Казанда да, районнарда да төрле буын вәкилләре өчен чаралар - дин әһелләре белән очрашулар, Рамазан аенда ифтарлар, Мәүлид бәйрәме уңаеннан төрле чаралар, балалар өчен Коръән, намаз уку буенча ярышлар уздырыла. Бу - мөселман өммәтен берләштерү чарасы да. Имамнар һәрвакыт ярдәм итәргә, киңәш бирергә әзер. Инде хаталанып, ялгышлык кылган мөселман кардәшләребезгә ярдәм итү өчен дә кулдан килгәннең барысы да эшләнә. Төрмәләрдә утыручы мөселманнар өчен намаз уку, ураза тоту һәм башка гыйбадәтләрне башкару өчен шартлар тудыру өстендә даими рәвештә эш алып барыла.

Бу эшләрнең нәтиҗәләре дә күренә. Елдан-ел ислам кушканча яшәүчеләр, мәчеткә йөрүчеләр саны арта. Рәсми саннар күрсәткәнчә, җинаятьләр саны кими. Мөселман өммәтенең уртак тырышлыгы һәм хокук саклау органнарының гадел эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак, киләчәктә дә шулай дәвам итәр, дип ышанасы килә.

*Чыганак: www.dumrt.ru*

# "ХӘЙРИЯЧЕ" КАРАКЛАР

**World Giving Index рейтингы күрсәткәнчә, дөньяда хәйрия белән шөгыльләнүчеләр арткан. Моңа аптырыйсы түгел, хәзер ярдәм күрсәтү ысуллары күп төрле.**

Хәйрия белән шөгыльләнүчеләр бүген социаль сайтларны да үз итә. Биредә кеше күп утыра, ярдәм итәргә теләүчеләр дә аз түгел. Ләкин бу өлкәне инде интернет белән эш итүче караклар да игътибардан читтә калдырмый. Республикабызның "Росток" хәйрия фонды хезмәткәре сүзләренә караганда, шуңа күрә дә халык сагайды. Кешеләр кайчак мәгълүматны тикшереп карамыйча ярдәм итүдән баш тарта. "Хәйрия авылларда авыр бара, чөнки анда яшәүчеләр өчен ул - беренчедән, ят, икенчедән, алар көн дә төрле алдау ысуллары турында ишетеп тора. Кешеләр белмәгән фондка 30-50 сум акча күчерергә дә җөрьәт итми", - дип аңлатты безгә фонд белгече.

### "КЛОН"НАРДАН САКЛАНЫГЫЗ!

Ялган "хәйрияче"ләр турында шәһәр кешесе дә яхшы белә. Ләкин ярдәм итмим дип кырт кискәнче, алар барлык документларны өйрәнә, реквизитларын тикшерә. Фонд оештыруга алынган кәгазьләрне "ЕГРЮЛ" (www.egrul.nalog.ru) сайтында өйрәнергә була. Белгечләр сүзләренә караганда, монда намуслы хәйрия оешмалары күчкән акча балансын, исәпләрен китерә, уздырылган акция, иганәчеләре турында мәгълүмат биреп бара. Аларның сайтында фикер калдыручылар да күп була. Элемтә өчен телефон номерлары, адреслар, фонд хезмәткәрләре исеме-вазифасы төгәл күрсәтелә.

Элек чын хәйрия оешмалары банк хисаплары белән эшләгән, ә караклар ешрак интернет-янчыклар кулланган. Ләкин бүген аферистларга да банк хисабын ачу авыр түгел. Әлбәттә, бу ышанычлы фондка электрон түләүләр ясамагыз дигәнне аңлатмый. Интернет-янчык, беренче чиратта, чит илдән акча күчерүчеләр өчен уңайлы.



Интернеттагы хәйрия сайтларын WHOIS дигән система буенча да тикшерергә мөмкин. Шик төшкән фондны эзләү системаларында карарга киңәш ителә. Яман аты чыккан оешмалар турында төрле форумда фикер алышу - гадәти күренеш. Үзем дә шулай берьюлы Казандагы "финанс пирамида"га эләгүдән сакланып калдым.

Хәер, караклар таныш фонд исеменнән эш итәргә дә тартынмый. "Күчерелмә", "клон"нар төп фондның реквизитларын үзенекенә алыштырып куя. Шуңа фондның номерына шалтыратып, реквизитларны җибәрүне сорарга, я фонд хезмәткәре белән берлектә саннар дөреслеген тикшереп чыгарга мөмкин.

### СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРДӘ КАРАКЛАР КҮПМЕ?

Монда хәйрия эшен фондлар түгел, ә билгеле бер төркем оештыра. Шуңа ярдәм таләп ителә торган кеше турында интернеттан һәм башка чыганаклардан белешергә киңәш ителә. Авыруның туганнары белән сөйләшергә мөмкин. Әгәр ярдәм чыннан да кирәк икән, алар сез биргән сорауларга теләп җавап бирәчәк, белгәннәрен яшермәячәк. Моннан тыш, кайсы клиникада дәвалану кирәген сорап, дәваханәгә чыга аласыз.

### КАРАКЛАР АБРУЙЛЫ ФОНДЛАРДАН КУРКА

Татарстанда ятимнәргә, физик мөмкинлекләре чикләнгән балаларга ярдәм итә торган "Наз" хәйрия фонды җитәкчесе Нурания Сәйфуллина сүзләренә караганда, уналтынчы елын эшләү дәверендә ул хәйриядә караклык очракларын күрмәгән. "Алар абруйлы фонд исеменнән эш итәргә алынмый, күрәсең", - ди Нурания ханым. Әле яңа гына аякка басып килә торган оешмаларны ялган фонд исәбенә кертмәс өчен, ул танылган хәйрия оешмаларына аларны үз канаты астына алырга, алар белән хезмәттәшлек итәргә тиеш, дип саный. Үзләре алар "Альпари", "Июль" оешмалары белән дус икән.

"Наз" фонды ярдәменә мохтаҗ балалар республикада шактый күп икән. Нурания Сәйфуллина әйтүенчә, фонд мондый балаларга үзе чыга. Ярдәм сорап килүчеләр дә бар. Шикле очраклар да аз түгел. Андый вакытта, Нурания ханым әйтүенчә, документлар яхшылап тикшерелә, социаль ярдәм идарәләре, сырхауханәләр белән сөйләшүләр алып барыла. "Акчаның кая, ничек китүе һәрвакыт контрольдә. Шуңа кешеләр мохтаҗларга ярдәм итәргә курыкмасын. Төрле караклык очракларыннан куркып, ярдәм итүдән баш тартмасыннар иде. Авыру балалар дәвалау курсын узгач та, без алар белән элемтәне өзмибез", - дип ассызыклады "Наз" фонды җитәкчесе.

***Миләүшә ЗАКИРОВА***
***Чыганак: www.intertat.ru***



## Рәсем бәйгесе уза!

***2012 елның 12 февраленә кадәр ТР мөселманнары Диния нәзарәте "Минем мәхәллә мәчете" бәйгесенә рәсемнәр кабул итә.***

Бәйгенең максаты - балаларны татар халкының рухи-әхлакый кыйммәтләре белән таныштыру, сәләтле яшүсмерләр белән эшләү һәм аларның иҗади башлангычларына ярдәм итү.

Бәяләү критерийлары: 1) рәсемнең бәйге темасына туры килүе; 2) беренче карауга тәэсир итүе; 3) сәнгатьчәлеге.

**Бәйгенең шартлары:**

*- барлык рәсемнәрнең дә сюжеты "Минем мәхәллә мәчете" темасына туры килергә тиеш;*

*- эшләр теләсә нинди стильдә башкарылырга мөмкин;*

*- рәсемнең исеме, авторның исем-фамилиясе, адресы һәм телефоны, туган елы һәм көне рәсем артына язылып куелырга тиеш;*

*- рәсемнәр кире кайтарылмый, аларны куллану хокукы оештыручыларда кала.*

Бәйгедә 16 яшькә кадәрге егетләр һәм кызлар катнаша ала.

Иң яхшы эшләргә Диния нәзарәте дипломнары һәм истәлекле бүләкләр тапшырылачак.

Рәсемнәр хат белән түбәндәге адрес буенча кабул ителә:

**420111 г. Казань, ул. Лобачевского, д. 6/27, ЦРО - ДУМ РТ ("На конкурс").**

**Сораулар өчен телефон: 89503146438 (Айнур).**

**Электрон почта: dummol@inbox.ru.**

# XVII ГАСЫРДАГЫ ТАТАР МӘДРӘСӘЛӘРЕ

**Татар халкының йөзләрчә еллар буе мәктәп-мәдрәсәләре булып, алар гасырлар буена татар халкын агартып килгән. Мәгълүм ки, җәмгыятьтәге үзгәрешләр халкыбыз тормышында азмы-күпме тискәре йогынты ясаган: китапларыбыз, мәдрәсәләр, зиратлар, изге урыннар юк ителгән.**

Шулай итеп, мирасыбызның күп өлеше югалган. Ләкин тырышканда кайбер фактларны, вакыйгаларны ачыкларга мөмкин әле. Соңгы елларда Истанбулның "Тупкапы" сарае китапханәсендәге кулъязмалар арасында татарларның башкаласы булган Сарай шәһәрендә 1290-1395 еллар арасында "Ногмания" исемле мәдрәсә булып, анда күчерелгән кулъязмалар саклануы ачыкланды.

Казан ханлыгы башкаласында да Колшәриф (Кол Мөхәммәдшәриф) тарафыннан ачылган мәдрәсә булып, аның шәкертләре 1552 елның 2 октябрендә остазлары белән бергә шәһит киткән.

XVI-XVIII гасырларда татар мөселманнарының, мәчетләре белән бергә, мәктәп-мәдрәсәләре дә җимерелүен безгә онытмаска кирәк. Кызганыч, хәзер дә татарча белем алу системасы юкка чыгарыла бара.


XVII гасырның икенче яртысына татар халкы 1552-1584 еллардагы азатлык сугышында алган яралардан өлешчә аякка баса башлый.

Шул вакытлардан татар мәдрәсәләре ачылу хакында хәбәрләр саклана. Мәсәлән, Казан арты авыллары Алатта, Симеттә; Минзәлә ягындагы Шыгайда; Касыйм ягындагы Әҗедә татар мәдрәсәләре булуга бәйле язма чыганакларны хәзергә ачыклый алдык; билгеле, аларның исемлеге болар белән генә чикләнмидер.

Халкыбызга аң-белем бирергә, аңа телләр үзләштерергә, китаплар укырга өйрәтүдә әлеге мәдрәсәләрнең әһәмияте биниһая зур булган.

Бу урында без аларның беренчесе - Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети исемле галим тарафыннан Симет авылында (Саба районы) ачылган мәдрәсә хакында сүз алып барырбыз. Фәнни әдәбиятта бу кешене Мортаза хафиз (абыз), Мортаза Симети исемнәре белән беләләр.

Аның кайсы елларда тууы һәм вафат булуы хакында төгәл мәгълүмат юк. Ләкин аның 1724 елда исән булуына Ризаэддин бине Фәхреддин бер мәгълүмат китерә.



XVII гасырның соңгы чирегендә Мортаза Симети ачкан мәдрәсәдә белем алган кешеләрнең XVIII гасырның беренче чирегендә галим, шагыйрь, педагог булып танылуы мәгълүм. Алар арасында Рәфикъ бине Таиб Курсави (Курсадан), Габдессәлам бине Урай (Олы Мәңгәрдән), Мансур бине Әнәс Борындыкый (Борындыктан), Әлмөхәммәд бине Сүкәй Шәмәки (16??-1742, август), Әгъзам Тенеки (Тенекидән), Габдеррәшид бине Кадермөхәммәд әс-Сабавый һ.б. булган (Ризаэддин бине Фәхреддин. Асар. I том. - Казан: Рухият, 2006. - 35 б.).

Бу шәхесләрнең остазлары Мортаза Симети - хаҗга барган кеше, аның хаҗга бару сәяхәтнамәсе дә сакланган. Ул үзе Казан ханлыгында, Ибраһим хан заманында аннан тарханлык ярлыгы алган атаклы бер нәселдән. Казан артында, Кама, Зәй, Кенәле буйларында бу нәселнең нәсел тармаклары киң таралган.

Мортаза Симети чама белән 1640 елларда туган була. Аның эшчәнлеге һәм ул ачкан мәдрәсәне тәмамлаган шәкертләр XVIII йөзнең өченче чирегенә хәтле татар мәгърифәте үсешенә зур өлеш кертә. Алар арасында иң танылган вәкил Мансур бине Әнәс Борындыкый була. Ул - шагыйрь, дәреслекләр авторы, нык иманлы имам булып, үз мәхәлләсе халкын көчләп чукындырудан саклап кала.

Аның тарафыннан язылган "Гавамил китабы" (1727) татар мәдрәсәләрендә күп еллар буе гарәп теле дәреслеге буларак кулланылган (Ризаэддин бине Фәхреддин. Асар. I том. - Казан: Рухият, 2006. - 39 б.). Соңгы елларда М.Борындыкыйның бер тарихи кулъязмасы да табылды (Гайнетдин М. Мансур Борындыкый // Иман нуры. - 2006. - Май. - № 4. - 17 б.). Ул кулъязмада Чыңгыз нәселеннән булган татар ханнары тарихына кагылышлы хәбәрләр язылган.

Мәдрәсәнең хәзерге Рязань өлкәсе Ермишино төбәге Әҗе авылында 1673 елда Тимергали Сафәров тарафыннан нигезләнүе турында язма мәгълүмат сакланган (Беләшев Аллаяр. Әҗе аулы хакында).

1698 елда Шыгай авылы мәдрәсәсен тәмамлап чыккан имам Мөхәммәдшәриф бине Сөләйман хәзрәт мәгълүм. Димәк, Шыгай авылында да мәдрәсә булуына дәлил бар.

Мортаза Симети шәкертләреннән Рафикъ Курсави нәселләре хәзерге Татарстанның Арча, Балтач, Саба, Теләче төбәкләрендәге авылларда күп мәдрәсәләр тоткан имамнар булып торган.

Габдессәлам бине Урай - шагыйрь, Ташкичә мәдрәсәсендә мөдәррис булган. Анда хәтта атаклы Батырша (1711-1755) хәзрәт тә укыган.

Әгъзам Тенеки 1733 елда исән булган. Ризаэддин Фәхреддин аның кыска төннәрдә ястү намазын уку шартлары турында язган китабы булу хакында хәбәр итә.

Гомумән алганда, Мортаза Симети мәдрәсәсе һәм шәкертләре мәгърифәтне һәм мәдәниятне күтәрүдә татар халкы тарихында якты эз калдырган.

***Марсель ӘХМӘТҖАНОВ,***
***филология фәннәре докторы,***
***Татарстанның атказанган фән эшлеклесе***

# БИСМИЛЛАЛЫ БАЛ

***Фәнис хәзрәт умартаны ачып җибәрде дә: "Сөбханалла!" - дип куйды. Бакча буйлап тыз-быз очкан бал кортларын, битлек-халат кигән килеш, оялды ишегеннән шүрләп күзәтеп торсам да, бу сүздән соң умарта эченә бакмый булдыра алмадым.***

Ундүрт рам кояшта гәрәбәдәй ялтыраган бал белән мөлдерәп тулган. Кәрәздәге бал кортларын әрекмән яфрагы белән генә сыпырып куып, хәзрәт рамнарны махсус тартмага сала башлады. Бишалтысы умартада бал кортларына кала икән. Кәрәздәге мөһерне олы үткен пычагы белән җәһәт кенә кисеп атып, бал аертып та күрсәтте. Җитезлегенә күз иярми. Шулай, бал кортларының үзләреннән дә җитез хәрәкәт итмәсәң, яшь бала карагандай карамасаң, бу йөз баш умартага ничек күз-колак булмак кирәк! "Коръәннең "Нәхел (Умарта кортлары)" сүрәсенең 68-69 нчы аятьләрендә әйтелгәнчә: "Раббың бал кортларына вәхи кылды: "Ий бал кортлары! Тауларда, агачларда вә кешеләр тора торган җайларда үзегезгә оя ясагыз! Соңра һәр җимеш чәчәкләреннән бал ашагыз һәм җыегыз вә итагать итеп, мин әмер кылган юлга керегез!" - дип. Бал кортлары кешеләр өчен эчләреннән төрле төстәге балларны чыгарып бирәләр, ул балларда ашар өчен тәме дә һәм кешеләр өчен шифасы да бар. Фикерли белгән кешеләр өчен бал кортларының эшендә зур гыйбрәт вә дөреслек бардыр. Ягъни, бал кортларына һичкем дәрес бирә алмас, ләкин кешеләр бал кортларыннан дәрес алалар". Аллаһ күрсәткән юллар буйлап очып, кешеләр өчен шифа булырлык төрле төстәге ширбәт җыюда - бу эшләрдә уйлый белгәннәр өчен бөек гыйбрәт, дәлилләр бардыр. Умартачылык - безнең нәселнең хәләл кәсебе. Ни тырышсам да, әтинең рекордына җитә алганым юк әле!" - ди Фәнис хәзрәт.

Мамадыш районының "Яшелтау" умартачысы Шакирҗан Миңнеханов - 1989 елда җиде тонна уңыш алып, 100 баш корт анасы сатып республикага танылган кеше. Терекөмештәй әнисе Нәсимәнең кушаматы да - "корт анасы". Хәзрәтнең 14 һәм 11 яшьлек уллары Дәнис белән Рәмис тә әтиләре янында бөтерелә, "татлы эш"нең хикмәтен өйрәнеп үсә. Мамадыш, Чаллы, Казанда клиентлары ел саен зарыгып көтеп тора бит бисмиллалы балны.

... Тәкъдир дигәннәре хак: X класстан соң умартачылыкка укыган Фәнис Чаллыга китә. КамАЗга слесарь булып эшкә керә, өйләнеп җибәрә. Шәһәрдә ундүрт ел яшәгәннән соң, язмыш аларны авылга дәшә. Күзгә бозлавык галәгә олы кайгы алып килә: ике нарасыен бер атага калдырып, хатыны Фәния автоһәлакәттә вафат була. "Сабырлыклар, түземлекләр биргән Аллаһы Тәгаләгә мең рәхмәт: ул вакытларны авыр төш итеп кенә искә алам. Бишектә имчәк бала елый, 4 яшьлек Дәнисем: "Әни кая, әни кайттымы әле, әни кирәк!" - дигән сүзләре белән үзәкләремне өзә. Намаз укыганда яныма утырттым да, ахирәт дөньясына киткән әнисенең рухына, дога өмет итүче башка әрвахларга да дога кылырга өйрәттем. "Син аларга шулай ярдәм итә аласың", - дидем. Ул үсә төшкәч энекәшенә аңлатты. Улларым биш вакыт намазларын калдырмый, инде тугызынчы ел шулай яшибез. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән узган ел хаҗ гамәле кылырга, Кара ташка да орынып кайтырга насыйп булды", - дип сөйли хәзрәт. Аны 2007 елда имам итеп сайлыйлар. Бергәләп намаз укырга озак урын таба алмый йөргәннән соң мәчетне... үз өендә ача. Җомга саен авыл картлары аның залына җыела хәзер. Авылның рухи үсешенә зур көч куя ул. "Узган ел авыл клубында азан әйтү бәйгесе үткәрелде. Әбиләр, апалар, ап-ак яулыкларын ябып, матур киемнәрен киеп, олы бәйрәмгә җыелгандай килде. Бер-берсен уздырып, бәет, мөнәҗәт әйттеләр, дога укыдылар.... Шаккаттык!" - ди Керәшен Пакшины муниципаль авыл җирлеге башлыгы Газинур Әскаров. Анда Фәнис хәзрәт үзе спонсор булган, кичәдә актив катнашучыларга Коръән китаплары, бүләкләр өләшкән. Яшерен-батырын түгел, "Яшелтау" - килмешәкләр авылы. 1948 елда Мәскәү әмере белән оешкан "Разумовский" совхозында дуңгызчылык нык алга китә. Хезмәт хакы түләүләре турында ишетеп, тирә-күрше авылларда таякка эшләүчеләр бирегә агыла. Ул вакытта никадәр генә гөрләсә дә, ясалма совхозның гомере озын булмый. Хәзер биредә 70 хуҗалыкта 238 кеше яши. Яртысы татар, яртысы рус. Ни христианнарның, ни мөселманнарның зиратлары юк. Вафат булучыларны һәркем үз авылына алып кайтып күмә. Авылның ир-атлары чыгып китеп эшли: Чита, Архангельск, Сочига ук барып җиттеләр инде. Бәхетне хәләл кәсеп белән шөгыльләнеп туган җирдә табарга кирәген гамәлләре, вәгазьләре белән аңлатырга омтыла эшмәкәр Фәнис Миңнеханов. Хәзрәткә мәхәлләсе белән алга таба да ислам динен куәтләп, изге гамәлләр кылып яшәргә, үзенә тиң яр табарга, Аллаһы Тәгаләнең сынауларын уңышлы узарга язсын, бәхет-шатлыклар гына юлдаш булсын.




**РӘСЕМДӘ:** ***Фәнис Миңнеханов уллары белән.***

**Алсу ДИЯР,**
**Мамадыш районы.**
**Автор фотосы.**

# Тамчылардан күл җыела



**2011 елның октябрендә ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлеге ("NEY" фотостудиясе белән берлектә) "Галәмне ишетәсем килә" дип исемләнгән хәйрия фотоакциясе уздырды. Акция дәвамында җыелган бар акча-керем (йөз мең сум) тумыштан колагы ишетмәү аркасында инвалид булып йөрүче 2007 елгы Әхмәтҗанова Мәдинә Ленар кызы счётына күчерелде.**

Операция уңышлы узды. Шулай да, операциядән тыш, тышкы приёмниклар һәм аккумулятор алу өчен акча кирәк. Аларның гомуми суммасы - **40 мең сум** тәшкил итә.

Тагын бер адым... һәм Мәдинә ишетә алачак. Бергәләшеп Мәдинәгә ярдәм итик!

Ярдәм итәргә теләүчеләр мөфтиятнең ярдәм күрсәтү һәм хәйрия бүлегенә мөрәҗәгать итә ала. Белешмәләр өчен телефон: ***89872639889 (Гөлнара).***

# Мәүлид кичәсенә чакырабыз!

***Хөрмәтле милләттәшләребез, дин кардәшләребез!***

4 февраль (раббигыль-әүвәл аеның уникенче көне) - пәйгамбәребез Мөхәммәдне (сгв) искә алу - Мәүлид көне булачак. Бу айда Мәүлид ашлары үткәрелә. Пәйгамбәребезнең (сгв) тормышы өйрәнелә, күпләп салаватлар әйтелә.

Пәйгамбәребезнең (сгв) яшәү рәвеше безнең барыбыз өчен дә олы үрнәк - якты маяк булып тора. Һәрберебез дә үзебездә Пәйгамбәребез (сгв) сыйфатларын тәрбияләргә омтылырга тиешбез.

Халкыбыз Мәүлид аен бик борынгылардан ук хөрмәтләгән. Күрше-күлән, туган-тумача, кардәш арасында динебез кушканча шәфкатьле, миһербанлы булу тагын да көчәйгән. Хәзер дә Мәүлидне хөрмәтләп, зурлап үткәрик! Шундый кичәләрнең берсе - Мәрҗани мәчете белән бергәлектә "Мөслимә" иҗтимагый оешмасы тарафыннан үткәреләчәк. Кичә 3 февраль (җомга) көнне көндезге сәгать икедә Мәрҗани мәчетендә узачак. Кичәдә имамнар, зыялылар, галимнәр чыгыш ясаячак. Килгән кунаклар мөнәҗәтчеләрне дә тыңлый алачак.

**Рәхим итегез! Бергәләп Мәүлид аен каршы алыйк!**

# "Рубин"да - мөселман егетләре

***www.business-gazeta.ru сайтына биргән әңгәмәсендә "Рубин" уенчысы Бибарс Натхо, Корбан Бердыев һәм Гёкдениз Караденизкебек үк, Рамазан аенда ураза тотуы турында әйтә.***

"Башка командага күчкәндә, аның белән һәм җирлеккә бәйле күренешләргә игътибар итәсең, билгеле. Ислам факторы минем карарга тәэсир итте", - ди узган сезонда "Рубин"ның иң яхшы уенчысы булып танылган Б.Натхо.

Бибарсның туган абыйсы Адәм болай дип тә сөйли: "Бибарс - дингә бик тә бирелгән кеше, мәчетләргә даими йөри. "Рубин"ның тренеры да ислам кануннарына буйсынучы кеше булгач, аңа бу нәтиҗәле тәэсир ясады".

Бибарс Натхо - Кавказ сугышыннан соң Госманлы дәүләтенә күчеп киткән чиркәсләр нәселеннән. Ул Кфар-Кама авылында туган (ул хәзер Израильгә карый). Карьерасында ул инде Израиль футболы тарихына керергә, яшьләр җыелма командасының беренче яһүд булмаган капитаны булырга өлгергән.

**Чыганак: www.altinurta.ru**



## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 21.01.2012 | 7:27 | 8:57 | 13:02 | 15:36 | 16:53 | 18:23 |
| Якшәмбе | 22.01.2012 | 7:25 | 8:55 | 13:02 | 15:37 | 16:55 | 18:25 |
| Дүшәмбе | 23.01.2012 | 7:24 | 8:54 | 13:02 | 15:39 | 16:57 | 18:27 |
| Сишәмбе | 24.01.2012 | 7:22 | 8:52 | 13:02 | 15:40 | 16:59 | 18:29 |
| Чәршәмбе | 25.01.2012 | 7:21 | 8:51 | 13:02 | 15:41 | 17:01 | 18:31 |
| Пәнҗешәмбе | 26.01.2012 | 7:19 | 8:49 | 13:02 | 15:43 | 17:03 | 18:33 |
| Җомга | 27.01.2012 | 7:17 | 8:47 | 13:02 | 15:44 | 17:05 | 18:35 |
| Шимбә | 28.01.2012 | 7:16 | 8:46 | 13:02 | 15:46 | 17:08 | 18:38 |

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №3 (120) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-523.

**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 19 гыйнвар көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**